Язучылар белән очрашу : [«Адымнар-Чаллы» 59 нчы күп телләрне укыту гимназиясендә китапханәче Роза Хәмидуллина белән очрашу] // Көмеш кыңгырау. – 2026. – № 7 (26 февраль). – Б. 2.

# Язучылар белән очрашу

**18нче февральдә «Адымнар-Чаллы» 59нчы күп телләрне укыту гимназиясендә яңа проект башланып китте. Гимназиябездә Чаллы язучылары белән җанлы очрашулар циклына старт бирелде.**

Беренче кунакларыбыз – Татарстанның Атказанган мәдәният хезмәткәре, «Ләйсән» әдәби берләшмәсе җитәкчесе, язучы Роза Хәмидуллина һәм шагыйрә Рушания Гыйләҗева булды.

Очрашу «түгәрәк өстәл» форматында үтте. 7А сыйныфы укучылары язучылар белән иркен әңгәмә кордылар, иҗат дөньясы серләре турында сораштылар. Язучылар укучыларга әдәби дәрес бирде.

Кунакларыбызны гимназия укучыларының «җанлы әңгәмә»дә актив катнашуы, үзләре язган шигырьләрен укулары сокландырды! Алар үзләренең басылып чыккан китапларын укучыларга тәкъдим итте. Язучыларыбызга мавыктыргыч әңгәмәләре өчен зур рәхмәт белдерәбез!

Әлеге циклны оештыручылар: гимназиянең китапханә җитәкчесе – Флюра Борһанова һәм мәктәпнең психологы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлфия Насыйбуллина. Киләсе очрашу – 18нче мартта! Тагын кызыклы кунак белән очрашу көтә. Килегез, бергәләп әдәбият дөньясын өйрәник!



Фото «Адымнар-Чаллы» гимназиясенең Вк төркеменнән.